ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 06.12.2023 1948 КАРАР

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 21 июлендәге 650 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон, «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законның 19 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 641-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 21 июлендәге 650 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.1. пунктындагы 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-башлангыч оешма эшчәнлеге туктатылган очракта, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия (алга таба лицензия) гамәлдән чыгарылган очракта, Дәүләт аккредитациясе гамәлдә булмауның тиешле белем бирү программасы буенча аның дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм ителгән очракта;».

1.2. Нигезләмәнең 3.1. пунктындагы 4 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- лицензия гамәлдә булуын туктаткан очракта.».

1.3. Нигезләмәнең 4.11. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм тиешле федераль белем бирү программасы нигезендә мөстәкыйль рәвештә эшләнә һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тарафыннан раслана. Мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән белем бирү программаларының эчтәлеге һәм планлаштырылган нәтиҗәләре федераль мәктәпкәчә белем бирү программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбән булмаска тиеш.».

1.3. Нигезләмәнең 6.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7. Белем алучы яисә балигъ булмаган укучы ата-аналар (законлы вәкилләр) инициативасы буенча белем бирү мөнәсәбәтләрен вакытыннан алда туктату «әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса» белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма алдында күрсәтелгән белем алучының нинди дә булса өстәмә, шул исәптән матди йөкләмәләре барлыкка килүгә китерми».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1948 от 06.12.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 08.12.2023 09:14

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>08.12.2023 - 09:27 | - |